”Туган ягым – яшел бишек” төбәкара фәнни-гамәли укытучылар конференциясен үткәрү турында нигезләмә

1. Гомуми мәгълүмат

Әлеге нигезләмә “Туган ягым – яшел бишек” төбәкара фәнни-гамәли конференциясен үткәрүнең максатын, бурычларын билгели; конференцияне оештыру, үткәрү, йомгаклау, җиңүчеләрне бүләкләү тәртибе белән таныштыра.

2. Конференциянең максаты

2.1. Конференциянең максаты – укытучыларның төрле фәннәр буенча эзләнү эшчәнлеге аша иҗади фикер йөртүләрен, интеллектуаль сәләтләрен активлаштыру.

3.Бәйгене оештыручылар

- Казан федераль университеты Идел буе төбәкара мәгариф хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү һәм яңадан әзерләү үзәге
- “ТАТМЕДИА” ААҖ “Чын мирас” журналы редакциясе

4. Бәйгене үткәрү шартлары һәм тәртибе

Катнашырга теләүчеләргә 2014 елның 14 нче февраленә кадәр таләпләргә туры килгән текстны, иске фоторәсемнәрне, **“Чын мирас” журналына 2014 елның икенче яртыеллыгына язылу турында квитанция күчерелмәсен** электрон адрес буенча (miraskonf@mail.ru) җибәрү шарт. Кабул ителгән эшләр махсус комиссия тарафыннан тикшереләчәк, фәнни яктан кызыклы эшләрнең авторлары (40-50 автор) 21 февраль көнне Азнакай шәһәренең Балалар иҗат йортына конференциянең **II этабына чакырылачак.**.

5. Катнашучылар

Конференциядә татар теле һәм әдәбияты, тарих укытучылары, мәктәп музейлары һәм китапханәләре хезмәткәрләре, туган төбәкне өйрәнүчеләр катнаша ала.

6. Конференция кысаларында түбәндәге секцияләр эшләячәк:

1. **Төбәк тарихы** (үзегез яшәгән район, шәһәр, авылларның тарихы яки төбәктә булган тарихи вакыйгалар).
2. **Шәхесләребез – туган як горурлыгы** (үз төбәгегездән чыккан күренекле мәгърифәтчеләр, язучы, шагыйрьләр һ.б. күренекле шәхесләрнең тормыш юлларына бәйле истәлекләр, аларның фәнни-иҗади эшчәнлекләре).
3. **Сәнгать** (төбәктәге декоратив-гамәли сәнгать: тегү-чигү, каюлы күн, зәркән, агачны кисеп бизәк ясау һ.б. осталарының иҗаты, фотоларда – тарих: тарихи шәхесләрне, борынгы милли киемнәрне, кыр эшләре барышын, тарихи биналарны, һөнәрчелекне тасвирлаган һәм **үзегез тарихи яктан кызыклы дип санаган иске фоторәсемнәр**, алар турында кыскача (1-2 бит) мәгълүмат).
4. **Әдәбият дәресләрендә – туган төбәк** (дәресләрдә туган җиргә, шәхесләренә мәхәббәт тәрбияләү, төбәктән чыккан әдип һәм шагыйрьләрнең иҗатын укыту методикасы, аларның иҗаты белән тәрбия чараларын оештыру).

7. Конференциядә катнашу тәртибе

7.1. Конференциядә укытучылар фәнни-эзләнү эшләре белән катнаша. Алар мөстәкыйль эшләнгән, мәгълүматлар анализланган, авторның үз карашы, үз фикере чагылырга тиеш.